ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Школьная, д.1 , д. Смак Корса, Арский
муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мэктэп ур, 1 нче йорт, Курса Почпак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366) 53-2-36 факс (84366) 53-2-36. E-mail Smk.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 12 » май 2025 ел** **№ 34**

**Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 6 декабрендәге “Сеҗе авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләреннән файдалану турында” 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 28 августындагы “Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы турында” 901 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы “Россия Федерациясе Һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында” 138 номерлы карары (29.03.2024 редакциясе), РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган РФдә янгынга каршы режим кагыйдәләре нигезендә, Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының **2024 елның 6 декабрендәге** “Сеҗе авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләреннән файдалану турында” 32 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 1 пунктына түбәндәге абзац өстәргә:

«Биеклеге 50 метрдан артыграк булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә һава пространствосыннан файдалану Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның Бердәм системасы оператив органы (алга таба - Вәкаләтле орган) рөхсәте белән гамәлгә ашырыла..

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә arsk.tatarstan.ru «җирлек» бүлегендә һәм Сеҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: ТР,Арча районы, Курса-Почмак авылы, Мәктәп урамы,1 йорт, Сеҗе авылы, Мәктәп урамы, 25 йорт.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Сеҗе авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р. В. Хамидуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СИЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ